РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БАЙРАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
422391 с. Байрашево, ул. Джалиля, 22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАЙРАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
422391 Байраш авылы, Җәлил урамы, 22

тел. (84373) 57-5-13, факс 57-5-13, e-mail: Bay.Tet@tatar.ru
ОГРН 1021606559072, ИНН/КПП 1638001543/163801001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**25 .11. 2025** **№ 2-1**

**2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Байраш авыл җирлеге бюджеты турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә Байраш авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1 Статья

1. 2026 елга Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Байраш авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга.:

1) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Байраш авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 2372,70 мең сум күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Байраш авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2372,70 мең сум күләмендә;

3) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Байраш авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0,00 мең сум күләмендә.

2. 2027 елга һәм 2028 елга Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Байраш авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга.:

1) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Байраш авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 2027 елга 2532,20 мең сум һәм 2028 елга 2700,90 мең сум күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Байраш авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2026 елга 2532,20 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 63,30 мең сум, һәм 2027 елга 2700,90 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 135,00 мең сум;

3) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Байраш авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 2026 елга 0,00 мең сум һәм 2027 елга 0,00 мең сум күләмендә.

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Байраш авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2 Статья

1. 2027 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Байраш авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Байраш авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген нульле Россия Федерациясе валютасында расларга.

2. 2028 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Байраш авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Байраш авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген нульле Россия Федерациясе валютасында расларга.

3. 2029 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Байраш авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Байраш авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген нульле Россия Федерациясе валютасында расларга.

3 Статья

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Байраш авыл җирлеге бюджетында 2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына фаразлана торган керемнәр күләмнәрен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 Статья

1.Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Байраш авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

1.Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Байраш авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга

3.Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Байраш авыл җирлеге бюджетының гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2026 елга 0 мең сум, 2027 елга 0 мең сум һәм 2028 елга 0 мең сум күләмендә расларга.

5 Статья

Субсидияләр юридик затларга (дәүләт (муниципаль учреждениеләргә), индивидуаль эшкуарларга һәм физик затларга – товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүчеләргә субсидияләрдән тыш, Тәтеш муниципаль районының Байраш авыл җирлеге Советы карары белән билгеләнгән тәртиптә бирелә.

6 Статья

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга Тәтеш муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле башка бюджетара трансфертлар күләмен муниципаль контрольне гамәлгә ашыру өлешендә төзелгән килешүләр нигезендә расларга:

2026 елга 1,00 мең сум күләмендә;
2027 елга 1,00 мең сум күләмендә;
2028 елга 1,00 мең сум күләмендә.

7 Статья

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Байраш авыл җирлеге бюджетында Тәтеш муниципаль районы бюджетыннан алынучыларны исәпкә алырга

1) җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр:
2026 елга-1645,10 мең сум күләмендә;
2027 елга - 1785,60 мең сум күләмендә;
2028 елга-1934,60 мең сум күләмендә.

2) территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган җирле үзидарә органнарына беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыруга РФ вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләр:
2026 елга-0,00 мең сум күләмендә;
2027 елга-0,00 мең сум күләмендә;
2028 елга-0,00 мең сум күләмендә.

8 Статья

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Байраш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары 2026 елда муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

9 Статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр

нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Байраш авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

10 Статья

Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

11 Статья

Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

12 Статья

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** **А.М. Гобәев**